КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 25 апрель г.Казань № 394

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 5 февраль, 89 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары дәүләт хезмәтләре, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләренә туры китерү план-графигына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары дәүләт хезмәтләре, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләренә туры китерү план-графигын раслау хакында» 2022 ел, 5 февраль, 89 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары дәүләт хезмәтләре, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләренә туры китерү план-графигына, аны яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә (карарга теркәлгән).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 5 февраль, 89 нчы карары белән расланды (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 25 апрель, 394 нче карары редакциясендә)

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары дәүләт хезмәтләре, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләренә туры китерү план-графигы

| Т/с | Дәүләт (муниципаль) хезмәте, аны күрсәтү өчен җаваплы орган (оешма) исеме | Күрсәтү срогы |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы | |
| 1.1. | Медицина эшчәнлеген лицензияләү (медицина оешмалары һәм сәламәтлек саклауның хосусый системасына керә торган башка оешмалар, «Сколково» инновацион үзәге территориясендә, федераль башкарма хакимият органнары буйсынуындагы оешмалар, федераль закон белән хәрби һәм аңа тиңләштерелгән хезмәт каралган федераль башкарма хакимият органнары оешмалары, шулай ук югары технологияле медицина ярдәме күрсәтү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар тарафыннан гамәлгә ашырыла торган күрсәтелгән эшчәнлектән тыш) | 2023 елның 30 декабре |
| 1.2. | Каникул вакытында балаларның ялын оештыру | 2023 елның 30 сентябре |
| 1.3. | Түләүсез теш протезлары буенча социаль ярдәм күрсәтү | 2023 елның 30 сентябре |
| 1.4. | Опека, попечительлек (шул исәптән башлангыч опека һәм попечительлек) билгеләү, опекунны (попечительне) үз бурычларын үтәүдән азат итү | 2023 елның 30 сентябре |
| 1.5. | Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешма тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр билгеләнгән критерийлар буенча сыйфатның туры килүен бәяләү | 2023 елның 30 августы |
| 1.6. | Суд тарафыннан хокукка сәләтсез яисә хокукка сәләте чикләнгән дип танылган затныкы булган күчемсез мөлкәтне алу буенча алыш-бирешләр кылуга (шул исәптән алмаштыру яисә бүләк итү) опекунга (попечительгә) беренчел рөхсәт бирү | 2023 елның 30 сентябре |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 1.7. | Суд тарафыннан хокукка сәләтсез яисә хокукка сәләте чикләнгән дип танылган балигъ булган яшьтәге тәрбияләнүче зат исеменнән кредит шартнамәсен һәм заем шартнамәсен төзүгә (төзүгә ризалык бирүгә) алдан рөхсәт бирү, тәрбиядәге затны карап тоту яки торак урынны белән тәэмин итү һәм сатып алына торган урынны залогка (ипотекага) тапшыру максатларында | 2023 елның 30 сентябре |
| 1.8. | Суд тарафыннан хокукка сәләтсез яисә хокукка сәләте чикләнгән дип танылган зат мәнфәгатьләрендә гомерлек рента шартнамәсен төзүгә алдан рөхсәт бирү | 2023 елның 30 сентябре |
| 1.9. | Суд тарафыннан хокукка сәләтсез яисә хокукка сәләте чикләнгән дип танылган  затның кредит оешмасында булган счеттагы акчалар счетларын ябуга, салдырып алуга, күчерүгә, тотуга алдан рөхсәт бирү | 2023 елның 30 июне |
| 1.10. | Суд тарафыннан хокуктан файдалануга сәләтсез яисә хокуктан файдалану сәләте чикләнгән дип танылган зат исеменнән мөлкәт өлешен билгеләүгә (бирүгә) алдан рөхсәт бирү | 2023 елның 30 июне |
| 1.11. | Суд тарафыннан хокукка сәләтсез яисә хокукка сәләте чикләнгән дип танылган затлар исеменнән сатып алуның өстенлекле хокукыннан баш тартуга алдан рөхсәт бирү | 2023 елның 30 июне |
| 1.12. | Варис балигъ булган, Суд тарафыннан хокукка сәләтсез яисә хокукка сәләте чикләнгән дип  танылган граждан булган очракта, мирасны алудан баш тартуга алдан рөхсәт бирү | 2023 елның 30 августы |
| 1.13. | Хосусыйлаштыру тәртибендә торак урын сатып алудан баш тартуга һәм әлеге торак урынны хосусыйлаштыруга хокукы булган башка затлар тарафыннан милеккә алу өчен ризалык бирүгә суд тарафыннан хокукка сәләтсез яисә хокукка сәләте чикләнгән дип танылган зат исеменнән алдан рөхсәт бирү | 2023 елның 30 августы |
| 1.14. | Суд тарафыннан хокукка сәләтсез яисә хокукка сәләте чикләнгән дип танылган затныкы булган мөлкәтне  наемга (арендага), түләүсез файдалануга тапшыруга алдан рөхсәт бирү | 2023 елның 30 августы |
| 1.15. | Гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре территориаль программасын гамәлгә ашыруда катнашучы Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы буйсынуындагы медицина оешмасына табибка язылу | 2023 елның 30 марты |
| 1.16. | Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнарын мәҗбүри медицина иминиятенең нигез программасына кертелмәгән махсуслаштырылган, шул исәптән югары технологияле медицина ярдәме күрсәтү өчен медицина оешмаларына җибәрү | 2023 елның 30 сентябре |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 1.17. | Суд тарафыннан хокукка сәләтсез яисә хокукка сәләте чикләнгән дип танылган затларны стационар хезмәт күрсәтүгә җибәрелгән гражданнар өчен билгеләнгән интернат-йортка җибәрү турында карар кабул итү | 2023 елның 30 декабре |
| 2. | Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы | |
| 2.1. | Дәүләт милкендәге җирләрдән яисә җир кишәрлегеннән файдалануга рөхсәт бирү җир кишәрлекләре бирмичә һәм сервитут, гавами сервитут билгеләмичә | 2023 елның 30 сентябре |
| 2.2. | Җирләрне яисә җир кишәрлекләрен билгеле бер категориягә кертү яисә җирләрне яисә җир кишәрлекләрен бер категориядән икенчесенә күчерү | 2023 елның 30 сентябре |
| 2.3. | Дәүләт милкендәге җирләрне һәм (яисә) җир кишәрлекләрен һәм хосусый милектәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү | 2023 елның 30 мае |
| 2.4. | Дәүләт милкендәге җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү | 2023 елның 30 июне |
| 2.5. | Дәүләт милкендәге җир кишәрлекләрен милеккә, арендага, даими (чикләнмәгән вакытта) файдалануга, түләүсез файдалануга сатулар үткәрмичә бирү | 2023 елның 30 мае |
| 2.6. | Дәүләт милкендәге җир кишәрлеген милеккә түләүсез бирү | 2023 елның 30 июне |
| 2.7. | Дәүләт милкендәге җир кишәрлеген сатуларда бирү | 2023 елның 30 сентябре |
| 2.8. | Арендалана торган мөлкәтне милеккә сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда кече һәм урта эшкуарлык субъектлары арендалый торган дәүләт милкендәге күчемсез мөлкәтне бирү | 2023 елның 30 сентябре |
| 2.9. | Дәүләт милкендәге җир кишәрлегенә сервитут (гавами сервитут) билгеләү | 2023 елның 30 мае |
| 2.10. | Территориянең кадастр планында җир кишәрлегенең яисә җир кишәрлекләренең урнашу схемасын раслау | 2023 елның 30 июне |
| 2.11. | Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләрен физик яисә юридик затларга - күчемсез милек объектлары милекчеләренә арендага яисә милеккә бирү | 2023 елның 30 октябре |
| 2.12. | Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр категориясеннән җир кишәрлеген башка категориягә күчерү | 2023 елның 30 октябре |
| 2.13. | Татарстан Республикасы махсуслаштырылган торак фонды составыннан торак урыннарын кертү һәм төшереп калдыру | 2023 елның 30 ноябре |
| 2.14. | Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәтне дәүләт хуҗалык алып бару хокукында унитар предприятиеләренә теркәү, Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә, Татарстан Республикасы дәүләт казна предприятиеләренә оператив идарә итү хокукында раслау | 2023 елның 30 ноябре |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 2.15. | Татарстан Республикасы казнасы милкен тәшкил итүче торак урыннарны Россия Федерациясе гражданнарының милкенә тапшыру | 2023 елның 30 ноябре |
| 2.16. | Татарстан Республикасы милкендәге дини оешмаларга дини билгеләнештәге мөлкәтне милеккә тапшыру яисә түләүсез файдалану | 2022 елның 30 декабре |
| 2.17. | Татарстан Республикасы дәүләт милке реестрыннан мәгълүмат бирү | 2023 елның 30 декабре |
| 2.18. | Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлегеннән даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукын туктату турында карар кабул итү | 2023 елның 30 декабре |
| 2.19. | Газ бүлү челтәрләренең саклау зоналарын билгеләү, үзгәртү, туктату турында карар кабул итү | 2023 елның 30 декабре |
| 2.20. | Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәтне арендага тапшыруны килештерү | 2023 елның 30 декабре |
| 2.21. | Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәтне читләштерү буенча алыш-бирешләрне килештерү | 2023 елның 30 декабре |
| 2.22. | Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәтне түләүсез файдалануга тапшыру буенча алыш-бирешләрне килештерү | 2023 елның 30 декабре |
| 3. | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы | |
| 3.1. | Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы һәм Татарстан Республикасы карамагындагы оешмаларның педагог хезмәткәрләренә, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы муниципаль һәм хосусый оешмаларның педагог хезмәткәрләренә аттестация | 2023 елның 30 апреле |
| 3.2. | Каникул вакытында балаларның ялын оештыру | 2023 елның 30 апреле |
| 3.3. | Урта һөнәри белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына укырга гаризалар кабул итү һәм теркәү | 2023 елның 30 мае |
| 3.4. | Өстәмә гомуми белем бирү программасы буенча укуга язылу | 2023 елның 30 мае |
| 3.5. | Китапханә хезмәтеннән файдаланучыларга китапханә, библиография һәм мәгълүмат бирү хезмәте күрсәтү | 2023 елның 30 сентябре |
| 3.6. | Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү | 2023 елның 30 августы |
| 3.7. | Татарстан Республикасының авыл торак пунктларында урнашкан Татарстан Республикасының дәүләт яки муниципаль мәдәният, сәнгать һәм кинематография оешмаларына эшкә кергән яшь белгечләргә бер тапкыр бирелә торган пособие түләү | 2023 елның 30 сентябре |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 4. | Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы | |
| 4.1. | Дәүләт милкендәге җирләрдән яисә җир кишәрлегеннән файдалануга рөхсәт бирү җир кишәрлекләре бирмичә һәм сервитут, гавами сервитут билгеләмичә | 2023 елның 30 декабре |
| 4.2. | Дәүләт милкендәге урман кишәрлкләрен сатулар үткәрмичә генә арендага бирү | 2023 елның 30 декабре |
| 4.3. | Агач әзерләү һәм урман үсентеләрен үз ихтыяҗлары өчен сату-алу шартнамәсе проектын әзерләү турында карар кабул итү | 2023 елның 30 декабре |
| 4.4. | Урман фонды җирләре чикләрендә сатулар үткәрмичә генә арендага урман кишәрлеген бирү | 2023 елның 30 декабре |
| 4.5. | Урман патологиясе тикшерүе актларын раслау | 2023 елның 30 декабре |
| 5. | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | |
| 5.1. | Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы һәм Татарстан Республикасы карамагындагы оешмаларның педагог хезмәткәрләренә, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы муниципаль һәм хосусый оешмаларның педагог хезмәткәрләренә аттестация | 2023 елның 30 апреле |
| 5.2. | Каникул вакытында балаларның ялын оештыру | 2023 елның 30 апреле |
| 5.3. | Мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләренә балаларны исәпкә кую һәм җибәрү | 2023 елның 30 апреле |
| 5.4. | Өстәмә гомуми белем бирү программасы буенча укуга язылу | 2023 елның 30 апреле |
| 5.5. | Гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмаларына күчерү турында гаризалар кабул итү | 2023 елның 30 мае |
| 5.6. | Урта һөнәри белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына укырга гаризалар кабул итү һәм теркәү | 2023 елның 30 мае |
| 5.7. | Опека, попечительлек (шул исәптән башлангыч опека, попечительлек) билгеләү, опекунны (попечительне) үз бурычларын үтәүдән (балигъ булмаганнарга карата) азат итү | 2023 елның 30 сентябре |
| 5.8. | Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче Россия Федерациясе гражданнарына уллыкка алу мөмкинлеге турында бәяләмә бирү һәм уллыкка алучыларга кандидат буларак исәпкә кую | 2023 елның 30 мае |
| 5.9. | Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар оешмаларында булган баланы (балаларны) Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче балигъ булган гражданнар гаиләләренә вакытлыча тапшыру мөмкинлеге турында бәяләмә бирү | 2023 елның 30 мае |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 5.10. | Балигъ булмаган баланы карап тоту яисә тәэмин итү максатларында балигъ булмаган зат исеменнән кредит шартнамәсе һәм заем шартнамәсе төзүгә (ризалык бирүгә) алдан рөхсәт бирү һәм сатып алына торган урынны залогка (ипотекага) тапшыру өчен алдан рөхсәт бирү | 2023 елның 30 июне |
| 5.11. | Балигъ булмаган затның банкта яисә башка кредит оешмасында урнашкан счетларын ябуга, салдырып алуга, күчерүгә, тотуга алдан рөхсәт бирү | 2023 елның 30 июне |
| 5.12. | Балигъ булмаган затның күчемле мөлкәтен читләштерү буенча алыш-бирешләрне башкаруга алдан рөхсәт бирү | 2023 елның 30 июле |
| 5.13. | Балигъ булмаган затның күчемсез милеген тартып алу буенча килешүне гамәлгә ашыруга алдан рөхсәт бирү | 2023 елның 30 июле |
| 5.14. | Балигъ булмаган исеменнән сатып алуның өстенлекле хокукыннан баш тартуга алдан рөхсәт бирү | 2023 елның 30 августы |
| 5.15. | Законлы вәкилгә балигъ булмаган баланың мөлкәт өлешен билгеләүгә (бирүгә) рөхсәт бирү | 2023 елның 30 августы |
| 5.16. | 16 яшькә җитмәгән затка (затларга) никахлашуга рөхсәт бирү | 2023 елның 30 сентябре |
| 5.17. | 14 яшькә җиткән гражданга җиңел хезмәт башкаруга рөхсәт бирү | 2023 елның 30 сентябре |
| 5.18. | Ундүрт яшькә җитмәгән баланың исемен һәм (яисә) фамилиясен үзгәртүгә рөхсәт бирү | 2023 елның 30 октябре |
| 5.19. | Балигъ булмаган баланың мөлкәтенә карата мәсьәләләрне хәл итү өчен өченче затка ышанычнамә рәсмиләштерүгә рөхсәт бирү | 2023 елның 30 октябре |
| 5.20. | Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, алар арасыннан булган затларны, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар категориясенә караган затларны, алар 23 яшькә җиткәч, исемлеккә кертү һәм махсуслаштырылган торак фондының торак урыннары белән тәэмин ителергә тиешле | 2023 елның 30 ноябре |
| 5.21. | Балигъ булмаган затның милек объектына милек хокукын туктатуга рөхсәт бирү | 2023 елның 30 ноябре |
| 5.22. | Дәүләт йомгаклау аттестациясе нәтиҗәләре турында мәгълүмат бирү | 2023 елның 30 июне |
| 5.23. | Опекун (попечитель) гаиләсендә һәм тәрбиягә бала алучы гаиләдә баланы матди карап торуга айлык түләү билгеләү | 2023 елның 30 апреле |
| 5.24. | Элек балигъ булмаган бала анда теркәлгән булган торак урынны гражданнар милкенә тапшыруга (хосусыйлаштыруга) алдан рөхсәт бирү | 2023 елның 30 октябре |
| 5.25. | Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларны элек яшәгән торак | 2023 елның 30 декабре |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | урыннарында яшәү мөмин булмау фактын билгеләү | |
| 5.26. | Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар турында төбәк белешмәләр банкын төзү, алып бару һәм алардан файдалану | 2024 елның 30 гыйнвары |
| 5.27. | Балигъ булмаган баланы эмансипацияләү турында карар кабул итү (балигъ булмаганны тулысынча эшкә сәләтле дип игълан итү) | 2024 елның 30 гыйнвары |
| 6. | Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы | |
| 6.1. | Каникул вакытында балаларның ялын оештыру | 2023 елның 30 июне |
| 6.2. | Дәүләт ярдәменнән файдаланучы яшьләр һәм балалар берләшмәләренең республика реестрын алып бару | 2023 елның 30 июне |
| 6.3. | Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү | 2023 елның 30 июне |
| 7. | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы | |
| 7.1. | Электр энергетикасы субъектларының инвестиция программаларын раслау | 2023 елның 30 июне |
| 8. | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы | |
| 8.1. | Нәселле продукциягә (материалга) нәсел таныклыгы бирү | 2023 елның 30 июне |
| 9. | Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы | |
| 9.1. | Республика спорт федерацияләре статусын бирү өчен гомумроссия иҗтимагый федерациясенең республика спорт оешмаларын яисә структур бүлекчәләрен (төбәк бүлекләрен) дәүләт аккредитациясе | 2023 елның 30 мае |
| 9.2. | Каникул вакытында балаларның ялын оештыру | 2023 елның 30 апреле |
| 9.3. | Спорт судьяларының квалификация категорияләрен бирү | 2023 елның 30 апреле |
| 9.4. | Спорт разрядларын бирү | 2023 елның 30 апреле |
| 9.5. | Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү | 2023 елның 30 августы |
| 9.6. | Татарстан Республикасы территориясендә тренерларга, физик культура һәм спорт өлкәсендә белгечләргә квалификация категорияләре бирү | 2023 елның 30 октябре |
| 9.7. | Спорт әзерлеге программасына язылу | 2023 елның 30 июне |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 10. | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы | |
| 10.1. | Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү | 2023 елның 30 ноябре |
| 10.2. | Капиталь төзелеш объекты төзелешенә рөхсәт бирү (шул исәптән капиталь төзелеш объекты төзелешенә рөхсәткә үзгәрешләр кертү һәм Мондый рөхсәтнең гамәлдә булу срогын озайтуга бәйле рәвештә капиталь төзелеш объекты төзелешенә рөхсәт итүгә үзгәрешләр кертү) | 2023 елның 30 ноябре |
| 10.3. | проект документларына һәм инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы | 2023 елның 30 апреле |
| 10.4. | Территорияне планлаштыру документларын әзерләү һәм раслау | 2023 елның 30 августы |
| 10.5. | Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү | 2023 елның 30 августы |
| 10.6. | Татарстан Республикасының ике һәм аннан да күбрәк муниципаль берәмлекләре (шәһәр округлары, муниципаль районнары) территорияләрендәге су объектында ясалма җир кишәрлеген файдалануга тапшыруга рөхсәт кәгазе бирү | 2023 елның 30 ноябре |
| 10.7. | Татарстан Республикасының ике һәм аннан да күбрәк муниципаль берәмлекләре (шәһәр округлары, муниципаль районнары) территорияләрендәге су объектында ясалма җир кишәрлеге төзү эшләрен башкаруга рөхсәт кәгазе бирү | 2023 елның 30 ноябре |
| 10.8. | Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә инвестиция программаларын раслау | 2023 елның 30 октябре |
| 10.9. | Кайнар су белән тәэмин итүне, салкын су белән тәэмин итү һәм (яисә) су агызуны гамәлгә ашыручы оешмаларның инвестиция программаларын раслау | 2023 елның 30 ноябре |
| 11. | Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы | |
| 11.1. | Татарстан Республикасы территориясендә җиңел такси белән пассажирлар йөртү һәм багаж ташу эшчәнлеген гамәлгә ашыруга рөхсәт кәгазе бирү (аны яңадан рәсмиләштерү, рөхсәт кәгазе дубликатын бирү) | 2023 елның 30 ноябре |
| 11.2. | Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү | 2023 елның 30 ноябре |
| 11.3. | Капиталь төзелеш объекты төзелешенә рөхсәт бирү (шул исәптән капиталь төзелеш объекты төзелешенә рөхсәткә үзгәрешләр кертү һәм Мондый рөхсәтнең гамәлдә булу срогын озайтуга бәйле рәвештә капиталь төзелеш объекты төзелешенә рөхсәт итүгә үзгәрешләр кертү) | 2023 елның 30 ноябре |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 11.4. | Даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклыкларны һәм даими ташулар маршруты карталарын рәсмиләштерү, даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклыкларны һәм даими ташулар маршруты карталарын яңадан рәсмиләштерү | 2023 елның 30 ноябре |
| 12. | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | |
| 12.1. | Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан дәүләт һәм муниципаль мәгариф оешмаларында балаларны карап торган һәм тәрбияләгән өчен ата-ана түләвенең бер өлешенә компенсация түләү | 2023 елның 30 апреле |
| 12.2. | Мәет җирләүгә социаль пособие түләү | 2023 елның 30 апреле |
| 12.3. | Татарстан Республикасында яшәүче, Россия Федерациясенең һәм (яисә) Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары буенча социаль ярдәм чараларына хокуклы булмаган «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнар нигезендә пенсиясе билгеләнгән пенсионерларга, 60 һәм 55 яшькә җиткән гражданнарга (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар), 2018 елның 31 декабренә торышы буенча күрсәтелгән федераль законнарда каралган пенсия билгеләү шартларына туры килүче, әмма 60 һәм 55 яшькә җитмәгән гражданнарга (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) айлык акчалата түләү билгеләү | 2023 елның 30 июле |
| 12.4. | Гражданнарның аерым категорияләренә торак урын өчен түләү чыгымнарын билгеләү һәм түләү, шул исәптән күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә, коммуналь һәм башка төр хезмәтләргә капиталь ремонт өчен түләү | 2023 елның 30 июле |
| 12.5. | Өч яшьтән җиде яшькә кадәрге (җиде яшьне кертеп) балага айлык акчалата түләү билгеләү һәм түләү | 2023 елның 30 апреле |
| 12.6. | Аз керемле гаиләдәге балага пособие билгеләү | 2023 елның 30 июле |
| 12.7. | Абонентка даими файдалануга бирелгән теркәлгән телефон элемтәсе челтәренең абонент линиясе, радио, күмәк антенна өчен түләү чыгымнарын каплауга субсидия билгеләү | 2023 елның 30 июне |
| 12.8. | Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләренә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү (бирү) | 2023 елның 30 мае |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 12.9. | «Россиянең мактаулы доноры» яисә «СССРның мактаулы доноры» билгесе белән бүләкләнгән гражданнарга еллык акчалата түләү бирү | 2023 елның 30 мае |
| 12.10. | Торак урыны һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидия бирү | 2023 елның 30 июне |
| 12.11. | Гражданны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану | 2023 елның 30 мае |
| 12.12. | «Хезмәт ветераны» исемен бирү | 2023 елның 30 июне |
| 12.13. | Күпбалалы гаилә статусын билгеләү (Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә таныклыгын бирү, гамәлне озайту һәм алмаштыру) | 2023 елның 30 мае |
| 12.14. | Инвалид бала өчен сатып алынган товарның булуын тикшерү акты бирү | 2023 елның 30 августы |
| 12.15. | Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү | 2023 елның 30 августы |
| 12.16. | Чернобыль АЭСындагы һәлакәт аркасында радиация йогынтысына дучар булган гражданнарга бердәм үрнәктәге (таныклык дубликатлары) махсус таныклыклар бирү | 2023 елның 30 августы |
| 12.17. | Түләүсез юридик ярдәм күрсәтүгә хокукны билгеләү өчен гаиләнең уртача исәпләнгән кереме яисә ялгыз яшәүче гражданның кереме күләме турында белешмә бирү | 2023 елның 30 августы |
| 12.18. | «Бөек Ватан сугышы ветераны» таныклыгын (таныклык дубликатын) бирү | 2023 елның 30 сентябре |
| 12.19. | «Маяк» җитештерү берләшмәсендә 1957 елгы авария һәм Теча елгасына радиоактив калдыкларны ташлау нәтиҗәсендә пычрануга дучар булган торак пунктлардан чыгып киткән гражданнарга таныклык (таныклык дубликаты) бирү | 2023 елның 30 сентябре |
| 12.20. | Семипалатинск полигонында атом-төш сынаулары нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар булган гражданнарга таныклык (таныклык дубликаты) бирү | 2023 елның 30 сентябре |
| 12.21. | Икенче бөтендөнья сугышы чорында фашистлар һәм аларның союздашлары тарафыннан төзелгән концлагерьлар, гетто, мәҗбүри тоту буенча башка урыннар өчен билгеләнгән социаль ярдәм чараларына хокук турында таныклык (таныклык дубликаты) бирү | 2023 елның 30 сентябре |
| 12.22. | Һәлак булган (вафат булган) сугыш инвалиды, Бөек Ватан сугышында катнашучы һәм сугышчан хәрәкәтләр ветеранының гаилә әгъзасы таныклыгын (таныклык дубликатын) бирү | 2023 елның 30 октябре |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 12.23. | Реабилитацияләнгән гражданнарны күмү чыгымнарын каплауны билгеләү | 2023 елның 30 ноябре |
| 12.24. | Реабилитацияләнгән гражданнарга телефон урнаштыру чыгымнарын каплауны билгеләү | 2023 елның 30 ноябре |
| 12.25. | Акланган гражданнарга йөрү белән бәйле чыгымнарны каплауны билгеләү | 2023 елның 30 ноябре |
| 12.26. | Бер үк вакытта туган өч һәм аннан да күбрәк яшь ярымга кадәр бала тәрбияләүче гаиләләргә айлык пособие билгеләү | 2023 елның 30 октябре |
| 12.27. | Биш һәм аннан да күбрәк 18 яшькәчә баласы булган, ата-ананың берсе яисә икесе дә инвалид булган һәм (яисә) балаларның берсе булса да инвалид бала булган гаилә әгъзаларына айлык пособие билгеләү | 2023 елның 30 октябре |
| 12.28. | Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның пенсияләренә һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең тиешле еллар эшләгән өчен пенсияләренә өстәмә түләү билгеләү | 2023 елның 30 июле |
| 12.29. | Даими чит тәрбиягә (ярдәм, күзәтчелек) мохтаҗ 18 яшькә кадәрге инвалид балаларга өстәмә айлык акчалата түләү билгеләү | 2023 елның 30 декабре |
| 12.30. | Бер үк вакытта өч һәм аннан күбрәк бала туганда бер мәртәбә бирелә торган пособие билгеләү | 2023 елның 30 октябре |
| 12.31. | Авыл җирендә, шәһәр тибындагы поселокларда, бала туганда даими яшәүче хатын-кызларга бер мәртәбә түләү билгеләү | 2023 елның 30 декабре |
| 12.32. | 18 яшькә кадәрге өч һәм аннан күбрәк баласы булган, тәрбиягә алган балаларны да кертеп, гаиләләрдәге балаларга субсидияләр билгеләү | 2023 елның 30 ноябре |
| 12.33. | Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт өчен кертем түләүгә чыгымнарны билгеләү | 2023 елның 30 декабре |
| 12.34. | Ятим балаларга, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларга һәм уку чорында атасын да, анасын да яки берсен генә югалткан затларга пособие, субсидия, стипендия билгеләү | 2024 елның 30 гыйнвары |
| 12.35. | Торак урыннан һәм (яисә) торак йорттан файдаланганда коммуналь хезмәтләрне кулланучы гражданнар тарафыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә коммуналь хезмәтләр күрсәткән өчен түләү күләмен үзгәртүнең билгеләнгән чик (максималь) индекслар күләменнән артып китүче коммуналь хезмәтләр өчен түләү күләменең факттагы артуына бәйле рәвештә компенсация билгеләү | 2024 елның 28 феврале |
| 12.36. | Вакцинадан соң өзлегүләр барлыкка килгәндә гражданнарга компенсация һәм пособие билгеләү | 2024 елның 28 феврале |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 12.37. | Айлык акчалата түләү билгеләү | 2024 елның 28 феврале |
| 12.38. | Хроник бөер эшчәнлеге җитешсезлеге белән интегүче, амбулатор гемодиализ ысулы белән дәвалану алучы затларга амбулатор гемодиализ үтү урынына транспортта бару һәм яшәү урынына кире кайту чыгымнарын һәм онкология авырулары белән интегүче затларга махсуслаштырылган онкология ярдәме күрсәтүче Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау системасының медицина оешмаларына дәвалану урынына транспортта бару һәм яшәү урынына кире кайту чыгымнарына компенсация билгеләү | 2024 елның 28 феврале |
| 12.39. | 14 яшьтән 18 яшькә кадәрге балигъ булмаган гражданнарны укудан буш вакытта, эш эзләүдә кыенлыклар кичерүче эшсез гражданнарны, урта һөнәри белемле яисә югары белемле һәм белем алу турында һәм квалификация турында документ бирелгән датадан ел дәвамында эш эзләүче 18 яшьтән алып 25 яшькә кадәрге эшсез гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру | 2023 елның 30 мае |
| 12.40. | Инвалидларны эш белән тәэмин итүдә ярдәм күрсәткәндә озатып йөрүне оештыру | 2023 елның 30 июле |
| 12.41. | Социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешма тарафыннан иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтү сыйфатын бәяләү | 2023 елның 30 октябре |
| 12.42. | Ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалануына юллама алу өчен Татарстан Республикасы пенсионерларының аерым категорияләрен исәпкә кую | 2023 елның 30 октябре |
| 12.43. | Социаль хезмәтләр күрсәтүчеләр тарафыннан гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат бирү | 2023 елның 30 ноябре |
| 12.44. | Татарстан Республикасында муниципаль вазыйфа биләүче затлар пенсиясенә өстәмә түләү һәм «Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, Татарстан Республикасында җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» һәм «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» Татарстан Республикасы законнары нигезендә муниципаль хезмәткәрләрне тиешле еллар эшләгән өчен пенсияләр билгеләү турында гражданнарның гаризаларын кабул итү һәм теркәү. | 2023 елның 30 ноябре |
| 12.45. | Татарстан Республикасында эшчәнлек өлкәсен (һөнәр) сайлап алу, эшкә урнашу, һөнәри уку һәм өстәмә һөнәри белем алу максатларында гражданнарга һөнәри юнәлеш бирү | 2024 елның 28 феврале |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 12.46. | Эшсез гражданнарны һөнәри укыту һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирү (башка җирлектә укуны кертеп) | 2024 елның 28 феврале |
| 12.47. | Татарстан Республикасында эшсез гражданнарга психологик ярдәм | 2024 елның 30 марты |
| 12.48. | Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләре юлламасы буенча эшкә урнашу өчен башка урынга күчеп киткәндә эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына һәм эшсез гражданнарга күченгәндә ярдәм күрсәтү; | 2024 елның 30 марты |
| 12.49. | Гражданнарга яраклы эш эзләүдә булышлык күрсәтү | 2024 елның 30 апреле |
| 12.50. | Эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләрне сайлап алуда булышлык күрсәтү | 2024 елның 30 апреле |
| 12.51. | Эшсез гражданнарга эшмәкәрлек эшчәнлеген башлап җибәрүдә булышлык күрсәтү (индивидуаль эшмәкәр буларак дәүләт теркәвенә алганда, оештырыла торган юридик затны дәүләт теркәвенә алганда, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алганда, физик затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә куйганда билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга, билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган һәм халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органары юлламасы буенча һөнәри укыган һәм өстәмә һөнәри белем алган гражданнарга бер тапкыр финанс ярдәме күрсәтүне кертеп) | 2024 елның 30 апреле |
| 12.52. | Татарстан Республикасында хезмәт базарында эшсез гражданнарны социаль адаптацияләү | 2024 елның 30 мае |
| 13. | Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы | |
| 13.1. | «Татарстан Республикасында яшәүченең картасы» проектын гамәлгә ашыруда катнашучы кредит оешмаларына Татарстан Республикасы халкының карталары реестрының веб-сервисыннан һәм Татарстан Республикасында яшәүченең картасын чыгару (кабат чыгару) өчен кирәкле мәгълүматтан файдалануга рөхсәт бирү | 2023 елның 30 марты |
| 14. | Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы | |
| 14.1. | Федераль милектәге һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында ясалма җир кишәрлекләре булдыруга рөхсәт бирү | 2023 елның 30 мае |
| 14.2. | Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләрне рәсмиләштерү, дәүләт теркәве һәм бирү, аларга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү, шулай ук аларны яңадан рәсмиләштерү | 2023 елның 30 ноябре |

| 1 | 2 | 3 |
